РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«25» декабрь 2025ел

№ 170

2026 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артыграк өзеклекләр белән гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 13 декабрендәге 1018 номерлы «2026 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Указы нигезендә, ҖЧҖ «Теләче» идарәче компаниясе» нең 2025 елның 23 декабрендәге 104 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Район халкы өчен торак хезмәтләре тарифларын кушымта нигезендә расларга һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Муниципаль торак фондының торак урынын наемга алган өчен бер квадрат метр өчен 20 сум 00 тиен күләмендә түләү күләмен билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында: http://tulachi.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» декабрендәге 170
номерлы карарына кушымта

2026 елга район халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Үлч. бер. | Күрсәтелә торган хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2026 алып 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 алып 31.12.2026 кадәр |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | кв.м | 6,18 | 6,89 |
| 2. | Торак бинага агымдагы ремонт | кв.м | 4,35 | 4,85 |
| 3. | Йорт яны территориясен тоту (үләннәрне чабу һәм җыю, кардан чистарту, түбәне кардан һәм боздан чистарту) | кв.м | 5,74 | 6,41 |
| 4. | Йорт эчендәге сантехник канализация челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв.м | 3,45 | 3,86 |
| 5. | Йорт эчендәге электр челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв.м | 1,67 | 1,84 |
| 6. | Су белән тәэмин итүнең гомумйорт системаларын агымдагы ремонтлау | кв.м | 0,65 | 0,73 |
| 7. | Төтенлекләргә техник хезмәт күрсәтү | кв.м | 0,61 | 0,68 |
| 8. | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | кв.м | 0,61 | 0,68 |
| 9. | Фасад газүткәргечләрен ремонтлау һәм аларны карап тоту | кв.м. | 0,54 | 0,6 |
| 10. | Дератизация | кв.м | 0,15 | 0,17 |
| 11. | Контейнер мәйданчыкларын тоту | | 0 | 0 |
| 12. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | | 0 | 0 |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев